ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘМЗӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

КАРАР

№ 18 «28» май 2021 ел

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 31 гыйнварындагы 43 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләрен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Кагыйдәләрнең 4 статьясындагы 13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Шәхси торак төзелеше өчен җир кишәрлекләренең чик күләме:

җир кишәрлегенең максималь күләме - 1500 кв.м;

җир кишәрлегенең минималь күләме - 1000 кв.м.

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен җир кишәрлекләренең чик күләмнәре:

җир кишәрлегенең максималь күләме - 5000 кв.м;

җир кишәрлегенең минималь күләме - 1000 кв.м.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырырга, шулай ук Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Әмзә авыл җирлеге
Советы Рәисе А.Ә. Насыйбуллин